**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№832**
**30.01.2026**

«Ел рәссамы - 2025»
шәһәр конкурс күргәзмәсен
үткәрү турында

Башкарма комитетның 2025 елның 29 октябрендәге 8861 номерлы Карары белән расланган 2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәрендә мәдәниятне үстерү муниципаль программасын үтәү йөзеннән, шәһәрдә сынлы сәнгатьне үстерүдәге яңа тенденцияләрне ачыклау һәм профессиональ рәссамнарга ярдәм күрсәтү максатыннан

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның мәдәният идарәсенә «Ел рәссамы - 2025» шәһәр конкурс күргәзмәсен «Г.М. Хәкимова исемендәге Яр Чаллы картиналар галереясе» муниципаль бюджет учреждениесендә 2026 елның мартында үткәрергә.

2. Расларга:

1) «Ел рәссамы - 2025» шәһәр конкурс күргәзмәсен үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) «Ел рәссамы - 2025» шәһәр конкурс күргәзмәсенең оештыру комитеты һәм эшләрне сайлап алу һәм җиңүчеләрне билгеләү буенча күргәзмә комитеты составларын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «Ел рәссамы - 2025» шәһәр конкурс күргәзмәсен оештыру һәм үткәрү чыгымнарын финанслауга акча бүлеп бирүне 2026 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Мәдәният» 08.01 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 140 000 (бер йөз кырык мең) сум күләмендә, 3 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                    Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2026 елның 30 гыйнварындагы
832 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Ел рәссамы - 2025»
шәһәр конкурс күргәзмәсен үткәрү турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «Ел рәссамы - 2025» шәһәр конкурс күргәзмәсе (алга таба – конкурс) сынлы сәнгать өлкәсендә Яр Чаллы шәһәрендә рәсем сәнгатенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү, шулай ук Чаллы рәссамнарының иҗади активлыгын стимуллаштыру һәм аларның иҗатын популярлаштыру максатларында үткәрелә.

2. Конкурсның бурычы – сәнгатьнең төрле жанрларында югары һөнәри осталык дәрәҗәсе белән аерылып торган, автор стиле үзенчәлегенә, яңалыкка һәм оригинальлеккә ия әсәрләрне ачыклау.

2 бүлек. Конкурсны үткәрү тәртибе һәм сроклары

3. Әсәрләр түбәндәге номинацияләр буенча карала:
1) рәсем сәнгате;
2) графика;
3) скульптура;
4) яңа исемнәр (яшь рәссамнарны күрсәтү);
5) декоратив-гамәли сәнгать;
6) халык сәнгате;
7) Яр Чаллы. Тарих һәм хәзерге заман.

Конкурс күргәзмәсендә катнашучыларга тәкъдим ителә торган эшләр тематикасына Яр Чаллы шәһәре төзелеше тарихын һәм шәһәрнең яңа образын кертергә тәкъдим ителә.

4. Конкурсны үткәрү өчен, составлары Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты һәм эшләрне сайлап алу һәм конкурста җиңүчеләрне билгеләү буенча күргәзмә комитеты төзелә.

5. Күргәзмә комитеты рәисе күргәзмә эшләрен сайлап алу көнендә үк күргәзмә комитеты әгъзалары арасыннан ачык тавыш бирү юлы белән сайлана.

6. Конкурска эшләрне сайлап алу кадәр күргәзмә комитеты тарафыннан 2026 елның 26 февралендә гамәлгә ашырыла.

7. Күргәзмә комитеты әлеге нигезләмәдә күрсәтелгән номинацияләр буенча конкурс җиңүчеләрен ачык тавыш бирү юлы белән, гади күпчелек тавыш нигезендә билгели. Бәхәсле очракларда һәм тавышлар тигез булганда, күргәзмә комитеты рәисенең тавышы хәлиткеч була.

Күргәзмә комитеты әгъзасы конкурста катнашкан очракта, номинациядә аның әсәрен карап тикшерү һәм сайлап алу аның тавышыннан башка гамәлгә ашырыла.

Күргәзмә комитеты карары утырышның беркетмәсе белән рәсмиләштерелә. Конкурсның абсолют җиңүчесе номинантлар арасыннан сайлап алынып, игълан ителә һәм Мәдәният хезмәткәрләре көненә багышланган тантаналы чарада бүләкләнә.

8. Конкурста сынлы сәнгатьнең теләсә кайсы төрендә эшләүче Яр Чаллы шәһәре рәссамнары, шул исәптән профессиональ рәссамнар катнаша ала. Башка шәһәрләрдән катнашучыларның әсәрләре күргәзмәгә куела ала, ләкин конкурста сайлап алуда катнашмый. Һәр катнашучыдан 2025 елда башкарылган, төрле дәрәҗәдәге күргәзмәләргә куелган икедән артык булмаган эш кабул ителергә мөмкин. Әсәрнең күләме 1,5 м х 1,5 м дан артмаска тиеш. Эшләр «Г.М. Хәкимова исемендәге Яр Чаллы картиналар галереясе» МБУда 2026 елның 24 февраленә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Яр Чаллы шәһәре, 52/16 (3/01) йорт, тел. 38-16-24.

9. Катнашучы түбәндәгеләрне рәсмиләштерә:

- «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 4 пункты нигезендә (конкурс үткәрү өчен мәгълүмат әзерләү һәм файдалану максаты белән) персональ мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы;

- конкурста катнашучы турында, бирелә торган заявка турында мәгълүматны, конкурста катнашучы турында башка мәгълүматны «Интернет» мәгълүмати-коммуникация челтәрендә бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык, шулай ук заявкадагы мәгълүматларны раслый торган мәгълүмат.

Рәссам агымдагы елда вафат булган очракта, аның әсәрләрен күргәзмәгә кую өчен туганнары тәкъдим итә ала, ләкин ул эшләр күргәзмә комитеты тарафыннан номинацияләрдә каралмый.

10. Эшләр түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә:

1) югары һөнәри осталык;

2) индивидуальлек;

3) тема һәм сюжетны үзенчәлекле хәл итү;

4) новаторларча якын килү;

5) үзенчәлекле иҗади фикерләү;

6) автор стиленең үзенчәлеге;

7) төрле дәрәҗәдәге (шәһәр, региональ, зональ, республика, Россия һәм халыкара) күргәзмәләрдә катнашу.

11. Һәр әсәр каталог мәгълүматлары белән бергә бирелергә тиеш.

## 3 бүлек. Конкурс йомгаклары

11. Җиңүчеләр дипломнар белән бүләкләнә.

12. Фондларны тулыландыру максатында, иң яхшы сәнгать әсәрләре «Г.М. Хәкимова исемендәге Яр Чаллы картиналар галереясе» МБУның фонд-сатып алу эксперт комиссиясе тарафыннан сатып алу өчен сайлап алына, даими саклау актлары һәм шартнамәләр белән рәсмиләштерелә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева